РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘР
СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2024 елның 8 октябре № 31

Түбән Кама шәһәр Советының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 08 августындагы 289-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының «Түбән Кама шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләр үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 18 ноябрендәге 59 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Карарга кушымтада:

4.7.4 пунктында «66 статьясындагы 12 өлешендә» сүзләрен «66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

4.10.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.10.4. Күчмә тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәнең 4.2.1 пунктындагы 2 пунктчасында каралган карар кабул ителә алмый.».

2. Түбән Кама шәһәр Советының «Түбән Кама шәһәре территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 18 ноябрендәге 60 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Карарга кушымтада:

4.6.4 пунктта «66 статьясындагы 12 өлешендә» сүзләрен «66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

4.9.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9.4. Күчмә тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәнең 4.2.1 пунктындагы 2 пунктчасында каралган карар кабул ителә алмый.».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге уставында билгеләнгән тәртиптә рәсми рәвештә игълан итәргә, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының шәһәр инфраструктурасын үстерү буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәр Мэры Р.Х. Муллин